| АЛЕКСЕЕВСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АЛЕКСЕЕВСК РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.12.2022 № 142

п.г.т. Алексеевское

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 19.07.2016 №45«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына социаль-икътисади үсеше стратегиясе турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 5 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы , Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2015 елның 18 декабрендәге 534 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) дәрәҗәсендә социаль-икътисадый үсешне стратегик планлаштыруны гамәлгә ашыру буенча методик тәкъдимнәрнен 4.2 бүлекчәсе ,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставы нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 19.07.2016 № 45 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына социаль-икътисади үсеше стратегиясе турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3 нче бүлекнең «2030 елга кадәр Алексеевск муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең төп күрсәткечләре»3.2.12 таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта);

1.2. 4 нче бүлекнең«Инвестиция проектлары исемлеге (төп капиталга инвестицияләр кертеп)» 4.3.1 таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә (2 нче кушымта);

1.3. 9 бүлекнен «2030 елга кадәр Алексеевск муниципаль районы Стратегиясенең максатчан ориентирлары» 8.1 таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә (3 нче кушымта);

1.4. 9 бүлекнең«Алексеевск муниципаль районы керемнәренең һәм чыгымнарының фаразланган бюджеты»8.2 таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә (4 нче кушымта);

1.5. 3.2.1 «Сәнәгать предприятиеләрен үстерү чаралары» таблицасын, 3.2.2. «Кулланучылар базарын үстерү буенча чаралар исемлеге» таблицасын, 3.2.3 «Төзелеш һәм ТКХ тармагында чаралар» таблицасын, 3.2.4 «Сәламәтлек саклауда чаралар исемлеге»таблицасын, 3.2.8 «Физик культура һәм спортны үстерү чаралары»таблицасын, 3.2.9 «Халыкны социаль яклау өлкәсендә чаралар»таблицасын, 3 нче бүлекнең 3.2.10«Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләргә һәм балаларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар һәм СЮКБО »таблицасын,4.2.1 «2016-2030 елларга авыл хуҗалыгын үстерүнең төп юнәлешләре» таблицасын, 4 нче бүлекнең 4.4.1 «ДБМУ«Биләр дәүләт тарих-археология һәм табигать музей-тыюлыгында туризмны үстерү чаралары планы »таблицасын, 5.1.2.1 « Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә чаралар»таблицасын, 5.1.3.1«Инвестицион җәлеп итүчәнлек һәм эшлекле активлык өлкәсендәге чаралар»таблицасын, 5 бүлекнең 5.1.4.3«Кеше капиталы, хезмәт базары һәм урбанизация өлкәсендәге чаралар» таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә (5 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет рәисе** **С. А. Демидов**